**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 14 апрель № 252

г. Казань

2010 – 2015 елларга Татарстан Республикасында мәгарифне үстерү буенча «Киләчәк» – «Будущее» стратегиясенең өченче этабын тормышка ашыру буенча 2015 елга чаралар планын раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2010 – 2015 елларга Татарстан Республикасында мәгарифне үстерү буенча «Киләчәк» – «Будущее» стратегиясен раслау турында» 2010 ел, 30 декабрь, 1174 нче карары белән расланган 2010 – 2015 елларга Татарстан Республикасында мәгарифне үстерү буенча «Киләчәк» – «Будущее» стратегиясен тормышка ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән 2010 – 2015 елларга Татарстан Республикасында мәгарифне үстерү буенча «Киләчәк» – «Будущее» стратегиясенең өченче этабын тормышка ашыру буенча 2015 елга чаралар планын (алга таба – Чаралар планы) расларга.

2. Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгына Чаралар планын үтәүне һәм аны тормышка ашыру буенча Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарының, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнарының, оешмаларның һәм учреждениеләрнең үзара хезмәттәшлеген оештыруны тәэмин итәргә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков